РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» март 2018 ел Буа шәһәре № 84/ИК-п

2018 нче елда савым сыеры булган
хуҗалыкларның санын арттыру максатында,
сыер тотуда чыгымнар өлешен каплауга
субсидия бирү тәртибен раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә эшчәнлегенең гомуми принциплары турында" гы Федераль Закон , 6 нчы октябрь, 2003 нче ел, № 131-ФЗ, «Авыл хуҗалыгы үсеше турында» Россия Федерациясе Федераль Законы, 29 нчы декабрь, 2006 нчы ел, № 264-ФЗ , «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» Федераль Закон, 7 нче июль 2003 нче ел, № 112-ФЗ нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты
**карар бирә:**

1. 2018 нче елда савым сыеры булган хуҗалыкларның санын арттыру максатында, сыер тотуда чыгымнар өлешен каплауга субсидия бирү тәртибен № 1нче кушымта нигезендә расларга.
2. 2018 нче елда савым сыеры булган хуҗалыкларның санын арттыру максатында, сыер тотуда чыгымнар өлешен каплауга субсидия бирү юл картасын № 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны интернет мәгълүмати – коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының http://buinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгару көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Камәртдинов

Кушымта №1
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
№ ___«___» _____ 2018 нче ел

**2018 нче елда савым сыеры булган хуҗалыкларның санын арттыру максатында, савым сыеры тотуда чыгымнар өлешен каплауга субсидия бирү тәртибе.**

## 1. Субсидия хокукын алу өчен шәхси ярдәмче хуҗалыклар категориясе һәм критерийлары.

1.1. Шәхси ярдәмче хуҗалык- авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге формасы түгел. Шәхси ярдәмче хуҗалык ул- гражданин һәм (яки) аның белән бергә яшәүче (яки) аның белән берлектә гамәлгә ашыручы гаилә әгъзаларның шәхси хуҗалык алып бару максатларында бирелгән җир участогыннан шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен туклану продуктлары әзерләүче.

1.2. Савым сыеры тотуда чыгымнар өлешен каплауга тиешле субсидия Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясе составына кергән торак пунктларда теркәлгән һәм 2018 нче елның 1нче гыйнварыннан алып 2018 нче елның 31 нче декабренә кадәр шәхси хуҗалыгында терлек башы санын арттыручы гражданнарга бирелә.

1.3. Субсидия гариза нигезендә бер тапкыр бирелә.

## 2. Субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе

2.1. ТР Буа муниципаль районы территориясендә субсидияләр белән тәэмин итү максаты- шәхси ярдәмче хуҗалыкларда савым сыерларының баш санын саклау һәм терлекчелек продукциясен җитештерүне стимуллаштыру.

2.2. Өстәмә түләү квартал нәтиҗәләре буенча һәм субсидияләр бирү нигезендә электрон хуҗалык китапларында теркәлгән һәр арткан савым сыерына 3000 сум исәбеннән башкарыла. Түләү квартал нәтиҗәләре буенча күчерелә.

2.3. Субсидия алу өчен гражданнар Буа муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документлар тапшыралар:

-1нче номерлы кушымта формасы нигезендәге гариза;

-мөрәҗәгать итүченең паспорт күчермәсе,;

-халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларын исәпкә алу электрон китабыннан күчермә;

-№2 нче кушымта формасы нигезендә, субсидияләр бирү исәп-хисап белешмә тәртибе;

-№ 3нче кушымта нигезендә, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда бер һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарга бирелгән субсидияне 2018нче елда максатчан куллануы;

-реквизитлары;

-2018 нче елга планлаштырылган ветеринария хезмәте үткәрү буенча белешмә;

-персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

-№5нче кушымта килешү нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетыннан савым сыеры тотуда чыгымнар өлешен каплауга субсидия бирү килешүе.

2.4. Район башкарма комитеты:

гаризаларны мөһере куелган, тегелгән һәм номерланган журналга тәртип буенча терки. Документлар гариза теркәлгәннән соң 10 көн эчендә карала.

2.3 пунктында күрсәтелгән тәртип буенча, документларның дөреслеген тикшерә;

2.3 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә, субсидия бирү өчен, исәп-хисап белешмәсе төзелә.

2.5. Башкарма комитет -бюджет акчаларын төп бүлүче, Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгының казначылык департаменты үзенең шәхси счетыннан, килешүгә кул куелганнан соң 7 көн эчендә, гражданнарның банк счетына №5 кушымта тәртибе нигезендә, субсидия күчерүне гамәлгә ашыра.

2.6. Гамәлдәге законнар нигезендә, гражданнар Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының субсидия бүлеп бирүдән баш тарту турындагы карарына шикаять бирергә хокуклы.

**3. Бюджет акчаларын максатчан куллану, исәп-хисапны контрольдә тоту.**

3.1. Максатчан билгеләнеше буенча тотылмаган һәм (яки) субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар керү фактларын ачыкланганда, бирелгән субсидия Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты кеременә алтмыш көн вакыт эчендә кайтарылырга тиеш.

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты кеременә күрсәтелгән акчаларны ирекле кайтарудан баш тарту очрагында, алар эзләтеп алынырга тиеш, ирексез рәвештә акчалар кире кайтарыла.

3.2. Район башкарма комитеты квартал саен Буа муниципаль районы Советына 2018 нче елда савым сыерларының баш санын арттыру максатыннан хуҗалыкларга бүлеп бирелгән бюджет чыгымнарын файдалану турында исәп -хисап чараларын тапшыра.

3.3. Субсидия алу өчен бирелгән документлар дөреслеге өчен җаваплылык гариза белән мөрәҗәгать итүче гражданнарга йөкләнә. Ришвәтчелеккә каршы законнарны үтәү Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата каралган җаваплылык чаралары гамәлдәге законнар белән билгеләнгән.

3.4. Бүленгән субсидиянең максатчан файдаланылуын контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты авыл җирлекләре башлыкларына йөкли.

3.5. №4 нче кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты белән авыл җирлеге Башкарма комитеты арасында субсидия алучы шәхси ярдәмче хуҗалыктагы терлекләрнең баш саны хисабы турында һәр квартал саен мәгълүмат бирү килешүе төзелә.

Кушымта № 1
2018 нче елда савым сыеры

булган хуҗалыкларда
баш санын арттыру максатларында
чыгымнар өлешен каплауга
субсидияләр бирү тәртибе

Буа муниципаль районының
башкарма комитеты җитәкчесенә
______________________________
______________________________
______________________________
______________________________
(Ф. И. О., яшәү адресы)

2018 елда савым сыеры булган хуҗалыкларның санын
арттыру максатында, савым сыеры тотуда чыгымнар өлешен каплауга
субсидия бирү турында гариза

Мин,______________________________________________________________,
(Ф. И. О.)
паспорт сериясе ____________ № ____________ кайчан бирелгән ________________________
______________________________________________________________________________
____________________________________, түбәндәге адрес буенча яшәүче:
______________________________________________________________________, телефон:
_____________________________________, ИНН_________________, Сездән 2018 нче елда шәхси хуҗалыгымда бер һәм аннан да күбрәк савым сыерын асрауга тотылган чыгымнарны каплау өчен (алга таба субсидия тексты буенча) миңа тиешле субсидияне бүлеп бирүегезне үтенәм. Минем шәхси хуҗалыгымда Татарстан Республикасы, шәхси хуҗалык адресы буенча урнашкан_________________________________________________, 01.01.2018 булган мәгълүматлар буенча, савым сыерлар саны __________________________ баш тәшкил итә .

1. Катнашу шартлары, субсидия бирү тәртибе белән таныштым , килешәм.

2. Субсидия биргән очракта йөкләмә алам:

- субсидия алганнан соң ,савым сыерларының баш санын ике ел дәвамында киметмәскә;

- исәп-хисапны тиешле вакытка өлгертергә;

- субсидияне максатчан билгеләнеше буенча – 3 ай дәвамында минем исәпкә акча кергәннән соң, шәхси хуҗалыгымда савым сыеры асрауга кулланырга.

Тәкъдим ителгән документлардагы яки аларның күчермәләрендәге бөтен мәгълүмат чын булып тора. Субсидия бирүдә катнашучы затларның документларны тикшерүенә, мин каршы түгел.

____________ /_____________ / «____» __________2018 нче ел.

(Имза) (Ф. И. О.)

Кушымта № 3
2018 нче елда савым сыеры булган хуҗалыкларда
баш санын арттыру максатларында

чыгымнар өлешен каплауга
субсидияләр бирү тәртибе

Йөкләмә
шәхси хуҗалыклары булган гражданнарга субсидияне савым сыерларының баш санын арттыру, 2018 нче елда чыгымнар өлешен каплауга тоту буенча субсидияне максатчан файдалану

Мин,______________________________________________________________, (Ф. И. О.) паспорт сериясе ____________ № ____________ бирелгән_________________________ ______________________________________________, түбәндәге адрес буенча яшәүче: ______________________________________________________________________, ИНН _____________________,йөкләмә алам:

1. Шәхси хуҗалыгымда , бер һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган (алга таба - субсидияләр) Башкарма комитет җитәкчесе исеменнән ______ № ______ « 2018 нче елга савым сыеры асрау өчен чыгымнар өлешен каплауга тоту,савым сыеры булган шәхси хуҗалыкларга баш санын арттыру максатларында нормативларын раслау "карары нигезендә гражданнарга бирелгән субсидияне катгый рәвештә максатчан билгеләнеше буенча, үземнең ___________________ адресы буенча урнашкан шәхси хуҗалыгымда савым сыеры асрауга тотарга:
2. Шәхси ярдәмче хуҗалыкка алынган субсидияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә район комиссиясе әгъзаларына, район Башкарма комитеты вәкилләренә каршылык күрсәтмәскә ,субсидия файдалану турында кирәкле мәгълүматны бирергә;
3. Субсидия алганнан соң, хуҗалыкта савым сыеры асрау, савым сыерының баш санын кимендә 2 календарь ел дәвамында киметергә ярамый;
4. 1-3 пунктларның йөкләмәләрен һәм имзаланган йөкләмәләр шартларын үтәмәгән очракта, алынган субсидияләрне максатчан кулланмау турында төзелгән акт нигезендә 60(алтмыш)көн эчендә алынган субсидияләрне Буа муниципаль районы җирле бюджетына кайтарып бирергә;
5. Йөкләмәләрдәге теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр язма рәвештә ике як тарафыннан имзаланган булуы шарт.Киресенчә булганда,РФ һәм РТ гамәлдәге законнары кулланылачак. Әлеге йөкләмәне ике як имзалаганда, төшенчәләр һәм билгеләмәләрдә аңлашылмаучанлык юклыгы турында шәрекли.

Мин, ____________________________, «Шәхси мәгълүматлар турында "№152- ФЗ 27.07.2006 ел, Федераль закон нигезендә, тәкъдим ителгән йөкләмәләрне төзегәндә һәм үтәгәндә ,мәгълүмат эшкәртүгә үземнең ризалыгымны белдерәм. Әлеге ризалык йөкләмә төзелгәннең бөтен срогына бирелә ( имзаланганнан соң 2 елга кадәр)гамәлдә була.

______________________________ (Ф. И. О.) Паспорт: сериясе________, № ___________ бирелгән: ____________________________ __________________________________ Яшәү адресы: __________________________ __________________________

______________________/________________/

Кушымта №4
2018 нче елда савым сыеры булган хуҗалыкларда
баш санын арттыру максатларында
чыгымнар өлешен каплауга

субсидияләр бирү тәртибе

Башкарма комитет хисабы

2018нче елда __________________ авыл җирлегендә терлекләрнең баш саны, әйдәп баручы шәхси ярдәмче хуҗалыкларда бер һәм аннан да күбрәк савым сыерларына чыгымнар өлешен каплауга тоту турында
«___» _________ 2018 елның торышына

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
_________ ________________
(имза) (Ф. И. О.)
«_____» ________________ 2018 ел

«Килешенде»
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
______________________
авылы җирлеге башлыгы

_____ _________________
(имза) (Ф. И. О.)
«_____»________________2018ел

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы _______________авылы җирлеге
ОКАТО ____________________

| № п\п | ЛПХ алучы ФИО | Яшәү урыны | Алган вакытка сыер саны | Отчет вакытына сыер саны | Сан арту |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | __ ___ 2018ел. | __ ___2018 ел. | __ ____2018 ел. |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

Мәгълүматларның дөреслеген раслыйбыз:

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
______________авылы җирлеге башлыгы ____ ___________
(имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
_________ ____авылы җирлеге баш хисапчысы

_______ ____________
(имза) (Ф.И.О.)

Кушымта № 2
2018 нче елда савым сыеры булган хуҗалыкларда
баш санын арттыру максатларында
чыгымнар өлешен каплауга

субсидияләр бирү тәртибе

Белешмә- хисап

Әйдәп баручы шәхси ярдәмче хуҗалыкларда 2018 нче елда савым сыерының баш санын арттыру өчен чыгымнар өлешен каплауга гражданнарга субсидия бүлеп бирү турында
«___» _________ 2018 нче елның торышына

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
________ _______________
(имза) (Ф. И. О.)
«_____» ________________ 2018нче ел

«Килешенде»
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
_______________________
авылы җирлеге башлыгы

_____ _________________
(имза) (Ф. И. О.)
«_____» ____2018 нче ел Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы ______________авылы җирлеге
ОКАТО _________________

| № п\п | ЛПХ алучы ФИО | Яшәү урыны | ИНН | Паспорт мәглүматлары | Савым сыерының саны,баш | Савым сыерының саны, баш | Бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка субсидия ставкасы, сум | Гомуми субсидия, сум. | Баш саны артуны тәэмин итү, саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Квартал башында | Квартал ахырында | 3000 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

Мәгълүматларның дөреслеген раслыйбыз:
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
_____________авылы җирлеге башлыгы ________ _______________
(имза) (ФИО)

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
_____________авылы җирлеге баш хисапчысы ________ _________________
(имза) (ФИО)

Кушымта № 5
2018 нче елда савым сыеры булган хуҗалыкларда
баш санын арттыру максатларында
чыгымнар өлешен каплауга

Килешү №___

Буа муниципаль районы бюджетыннан 2018 нче елда савым сыеры булган хуҗалыкларда, савым сыерларының баш санын арттыру максатларында чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү турында

Буа шәһәре “____”_______20____

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты, алга таба **«Башкарма комитеты»** (Татарстан Республикасы бюджеты акчалары бүлүче), җитәкчесе Р.Р.Камартдинов, гамәлдәге Устав нигезендә һәм _______________________________________________, алга таба « Субсидия алучы », ______________________________, гамәлдәге _______ нигезендә, алга таба ике як әлеге килешүне төзеде.

**1. Килешү предметы**

1.1 Килешү предметы,2018нче елда савым сыеры булган хуҗалыкларга савым сыерларының баш санын арттыруда чыгымнар өлешен каплауга тоту максатында___________(__________________________)сум.

**2. Ике як йөкләмәсе**

2.1 Башкарма комитет:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетыннан 1.1. пункты нигезендәге субсидияләр күләмендә, килешүне имзаланганнан соң 7 (җиде) эш көненнән соң бирелә;

Килешүне тормышка ашыру өчен, Субсидия алучының мәгълүматы һәм документлары кирәк.

2.2. Субсидия алучы тәэмин итә:

Субсидияне нәтиҗәле куллану;

Субсидия бирү тәртибен һәм гамәлдәге законнарны үтәү.

2.3. Башкарма комитетның таләбе буенча, финанс чыганагы булган субсидияне куллану турында раслаучы документлар, шулай ук чыгымнар турында оператив мәгълүмат тәкъдим итә.

**3. Ике як җаваплылыгы**

3.1. Гамәлдәге законнар нигезендә, әлеге килешүдәге йөкләмәләрне үтәмәве өчен ике як та җаваплы.

3.2. Килешү нигезендә,гадәттән тыш (форс- мажор) хәлләр килеп чыккан очракта, Яклар йөкләмәләрне тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.

Килешүдәге йөкләмәләрне аңлы рәвештә тиешенчә үтәү мөмкин булмаганда яки тиешле шартлар булмаганда, гадәттән тыш (форс-мажор) хәлләр килеп туганда, аерым алганда: хәрби гамәлләр, табигый бәла- казалар күздә тотыла, шул вакытта ике якка килешүдәге йөкләмәләрне үтәү мөмкинчелеге юк дип санала.

Гадәттән тыш (форс-мажор) хәлләр булганда, җаваплы ике як та бер-берсенә бу турыда өч көн вакыт эчендә хәбәр итәргә бурычлы.

3.3. Үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәгән очракта, ике як та Россия Федерациясе гамәлдәге законнары нигезендә җавап бирә.

**4. Килешүнең гамәлдә булу вакыты**

4.1. Әлеге килешү кул кую көненнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

**5. Башка шартлар**

5.1. Яклар арасында бәхәсләр сөйләшүләр юлы белән хәл ителә, ә килешмәгән очракта Татарстан Республикасы Буа район (шәһәр) судына тапшырыла .

5.2. Килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр, ике якның да ризалыгы белән кертелә һәм рәсмиләштерелә.

5.3. Әлеге килешү бер үк юридик көчкә ия, ике нөсхәдә.

## 6. Якларның реквизитлары

| | |
|---|---|
| ТР Буа муниципаль районы | Субсидия алучы: |
| Башкарма комитеты җитәкчесе | __________________________ |
| ____________/Р.Р. Кәмәртдинов/ | ___________/____________/ |
| «_____»________20___ ел. | «_____» ________ 20___ ел. |

Кушымта № 2
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Башкарма комитет карары
№___ «___» ________2018 нче ел

# ЮЛ КАРТАСЫ

2018 нче елда савым сыеры булган хуҗалыкларда баш санын арттыру максатларында чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе турында

| № п/п | Чаралар эчтәлеге | Үтәлү вакыты | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | БК ҮЗИДАРӘ гә шәхси хуҗалыкларда сыерлар саны турында № 4 кушымта нигезендә отчет тапшыру. | булган мәгълүматларга караганда, айның 1 числосына, квартал хисабыннан соң | Авыл җирлеге башлыгы<br>БМР БК ОМС бүлеге |
| 2 | №1,2,3,5 кушымталар нигезендә субсидия алучы гражданнар документлар җыю, комплектацияләү һәм БМР БК ОМС бүлегенә тапшыру. | айның 5 нче числосыннан да соңга калмыйча , квартал хисабыннан соң | Авыл җирлеге башлыгы<br>БМР БК ОМС бүлеге |
| 3 | Субсидия бирү турында гаризаны теркәү | гариза керү көнендә | БМР БК ОМС бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Кергән документларны карау һәм дөреслеген тикшерү. | гариза теркәү көненнән 10 көн исәбе | БМР БК ОМС бүлеге |
| 5 | Субсидияләр түләү өчен кирәк булган акчаларны исәпләү, исәп-хисап белешмәсе ясау . | | БМР БК ОМС бүлеге |
| 6 | БМР Башкарма комитетының субсидияләр бирү турында карар проектын хәзерләү. | | БМР БК ОМС бүлеге |
| 7 | БМР бюджетыннан (Кушымта №5 )килешүе нигезендә субсидияләр бирү һәм БМР БК субсидияләр бирү карары килешүе нигезендә,субсидияләр бирү. | килешүгә кул куйганнан соң җиде көн вакыт (Кушымта №5 ) һәм БМР БК субсидияләр бирү карары нигезендә | БМР Советы бухгалтерлык бүлеге исәбе |
| 8 | Йөкләмәләрнең максатчан куллану үтәлешен контрольдә тоту. | даими | БМР БК территориаль үсеш бүлеге<br>БМР исәп –хисап палатасы<br>Авыл җирлеге башлыгы |